# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Яңа Минзәләбаш авылында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

18.11.2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары буенча, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, I һәм II төркем инвалидларыннан тыш (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Яңа Минзәләбаш торак пунктында Яңа Минзәләбаш урамы буенча урнашкан зиратка илтүче юлларны төзекләндерү (сатып алу, төяү, ташу, материаллар салу, килешү буенча эшләү өчен түләү);

2) Яңа Минзәләбаш торак пунктында Яңа Минзәләбаш урамы буенча урнашкан терәк баганалары белән өстәмә яктырту нокталарын урнаштыру (сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләү өчен түләү);

3) чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), су җыю урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), чишмәгә юл ремонтлау (төзелеш материаллары алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) эскәмия сатып алу) Яңа Минзәләбаш торак пунктында Яңа Минзәләбаш урамында;

4) Яңа Минзәләбаш авылы Яңа Минзәләбаш урамы буенча урнашкан балалар уен мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

5) Яңа Минзәләбаш авылының Яңа Минзәләбаш урамы буенча урнашкан тимер-бетон бөҗралар, бөҗра төбе, янгынга каршы гидрант люк капкачлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)».

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Минзәләбаш авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга. http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштытрыга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы Башлыгы Р. Ә. Кәримов